**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский муниципальный район муниципальное образование «Мюдовское сельское поселение»**
**423063 п. Мюд, ул. Центральная д 27**
**тел. 884344 4-04-33**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы муниципаль беремлеге "Мюд авыл җирлеге"**
**423063 Мюд авылы**
**Центральная урамы, 27**
**тел. 884344 4-04-33**

КАРАР

№ 26 2021 елның 03 июнь

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»
2019 елның 13 ноябрендәге 105 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

РФ Салым кодексының 397 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай районы прокуратурасының 2021 елның 1 февралендәге 02-08-02 номерлы протестын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 105 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе» 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 мартындагы 23 номерлы карары;

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru 5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Т.В.Зюзина